**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН ТАБЫН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ
III ЧАКЫРЫЛЫШ XLVIII УТЫРЫШЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03 нче февраль, 2020 нче ел Югары Табын № 1

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы
Түбән Табын авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегендә муниципаль
хезмәт турындагы Нигезләмәне раслау хакында»
2019 елның «24» декабрендәге 4 нче номерлы карарына үзгәрешләр
һәм өстәмәләр кертү турында»**

Муниципаль хезмәт турындагы законнардагы үзгәрешләр нигезендә Түбән Табын авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның «24» декабрендәге 4 номерлы карарына (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Нигезләмәнең 7 бүлегендәге 3 бүлекчәнең 9 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«9. Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексының 17, 18 һәм 32 статьяларында каралган түләтүләр муниципаль хезмәткәрләргә коррупциячел хокук бозуны кылу турында мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча хезмәткә яраксыз булу чорларын, аның отпускта булуы чорларын санамыйча һәм коррупциячел хокук бозу кылган көннән соң өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән срокларга җинаять эше буенча тикшерү вакыты кертелми.»

б) Нигезләмәнең 7 бүлегендәге 2 булекчәнең 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә;

2. Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар муниципаль берәмлек Уставы нигезендә үз көченә керә.

***Түбән Табын авыл җирлеге Башлыгы, рәисе Р.Ш. Кыяметдинов***